| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11.01.2021** Кукмара ш. **№ 13**

«2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында

Кукмара муниципаль районында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. «2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын расларга.

2. Социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә гражданнарга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат җибәрүне (урнаштыруны) һәм «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6.11 статьясы нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүченең башка функцияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 11.01.2021 № 13 карарына кушымта

Муниципаль программа ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның Муниципаль заказчысы – координаторы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп башкаручылары | - Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Опека һәм попечительлек бүлеге, Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Мәдәният идарәсе<br>- Кукмара җирле инвалидлар иҗтимагый оешмасы;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>- «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ;<br>- «Кукмара РҮХ» ДАССУ;<br>- «Чиста шәһәр» ҖЧҖ;<br>- Җирлек башлыклары |
| Программаның максаты: | Социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру, шулай ук аерым категория гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | - Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чаралары күрсәтү<br>- Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренең тормыш сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү<br>- Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру |

| | |
|---|---|
| | - Муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү<br>- Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве өлешенә компенсацияне тулы күләмдә бирү<br>- Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга тулы күләмдә түләүсез туклану бирү<br>- Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре (алга таба – МГН) эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең Өстенлекле объектларның файдалану мөмкинлеге дәрәҗәсен күтәрү<br>- Җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркем кешеләре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021 – 2023 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр»;<br>2. 2021 – 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту»;<br>3. 2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит». |
| Программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләме | Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 108189,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән буенча: 2021 ел – 35148,8 мең сум, 2022 елда – 36051,3 мең сум, 2023 елда – 36989,8 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре – нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Программаны гамәлгә ашыру 2023 елга түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- хокукы булган һәм ярдәм билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын 100 процент дәрәҗәсендә бирүне тәэмин итү;<br>- район гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өлешен 98,8 процентка кадәр арттыру; |

| | |
|---|---|
| | - ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның барлык рәвешләрендә социаль түләүләр бирүне 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>- муниципаль районлагы инвалидларның гомуми санында тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеген уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 56,8 процентка җиткерү;<br>- муниципаль районлагы өстенлекле объектларның гомуми санында социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының инвалидлар һәм башка халыкның аз хәрәкәтләнүче төркеме өчен уңайлы булган объектлары өлешен 55,0 процентка җиткерү;<br>- физкультура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнә торган 6 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халык саныннан 15,0 процентка кадәр җиткерү; |

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсе характеристикасы. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

Әлеге Программа «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү Тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Кукмара муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 маендагы 238 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Программа, аларның эффектлылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатында, кабул ителгән норматив йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган һәм гражданнарга социаль ярдәм чараларының барлыкка килгән системаларын модернизацияләүне тәэмин итә торган эшчәнлек юнәлешләрен билгели.

Кукмара муниципаль районында 52000 нән артык кеше яши, шул исәптән 23% тан артыгы – балалар, 46% ы – эшкә яраклы яшьтәге, 31% ы – эшкә яраклы яшьтән өлкән гражданнар.

Муниципаль районда урнашкан халыкны социаль яклау системасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- гражданнарның төрле категорияләренә федераль һәм республика законнарында һәм муниципаль норматив-хокукый актларда каралган социаль түләүләр, компенсацияләр, субсидияләр, пособиеләр; гражданнарның, шул исәптән балаларның, балалы гаиләләрнең, инвалидларның, эшкә сәләтсез өлкәннәрнең тормыш дәрәҗәсен тәэмин итү өчен дәүләт социаль ярдәменең төрле төрләрен бирү;
- балигъ булмаганнарны һәм эшкә сәләтсез яки тулысынча эшкә сәләтле булмаган гражданнарны опекага һәм попечительлеккә алу;
- балаларга, шулай ук балалы гаиләләргә кайбер өстәмә чаралар күрү;
- халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан төрле социаль хезмәтләр күрсәтү;
- инвалидлар һәм башка халыкның аз хәрәкәтләнүче төркеме өчен файлану мөмкинлеге булган һәм уңайлы яшәү мохите булдыру.

Муниципаль районда халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр бүлешү шартларында гамәлгә ашырыла торган социаль йөкләмәләрен һәм бюджет системасы дәрәҗәләре буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын бирү буенча тиешле чыгым йөкләмәләрен вакытында һәм тулы күләмдә үтәү оештырылган.

Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте, муниципаль район башкарма хакимияте органнары тарафыннан халыкның керемнәрен арттыру буенча күрелә торган чаралар гаиләләрнең матди хәлен яхшырта һәм аз керемле гражданнар саны кимүгә китерә.

Республикадагы кебек үк, муниципаль районда да балигъ булмаган балаларны, шулай ук балалы гаиләләрне социаль яклау системасы үсеш алган.

Халыкны социаль яклау өлкәсендә муниципаль районда тормышка ашырыла торган дәүләт сәясәтенең өстенлекләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) халыкны социаль яклау өлкәсендә гражданнарга дәүләт хезмәтләре күрсәтүне ссыйфатка һәм һәркем файдалана алырлык булуга карата таләпләрдән чыгып камилләштерү;

2) гаиләдә баланы саклауны тәэмин итүче гаиләне социаль яклау системасын ныгыту, авыр тормыш ситуациясенә эләккән балаларның үсеше һәм тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның төрле формаларын үстерү;

3) гражданнарга, беренче чиратта ветераннарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү системасын камилләштерү;

4) инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре тарафыннан, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, тормыш эшчәнлегенең төп чикләүләреннән чыгып, тоткарлыксыз файдалану һәм хезмәт күрсәтүләр алу өчен, социаль инфраструктураның өстенлекле объектларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү.

Халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт социаль йөкләмәләренең үтәлешен камилләштерү, киң катлау файдаланучыларга сыйфатлы дәүләт хезмәтләрен алу мөмкинлеген арттыру яңа технологияләрне, инновацион алымнарны кертмичә, шулай ук дәүләт хезмәтләрен электрон рәвештә күрсәтүгә күчүдән башка мөмкин түгел.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыруның көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләрен, срокларын һәм этапларын тасвирлау

Хәзерге вакытта гамәлдәге законнар һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә билгеле бер вәкаләтләр нигезендә гражданнарның социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, шул исәптән муниципаль район эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып тора.

Программаның максаты – социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру, шулай ук аерым категорияләрдәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту

Программаның бурычлары:

- Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чаралары күрсәтү

- Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренең тормыш сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү

- Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру

- Муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве өлешенә компенсацияне тулы күләмдә бирү

- Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга тулы күләмдә түләүсез туклану бирү;

- Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре (алга таба – МГН) эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең Өстенлекле объектларның файдалану мөмкинлеге дәрәҗәсен күтәрү

- Җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркем кешеләре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру

Моннан тыш, җәмгыятьтә гаилә, бала, җаваплы ата-ана кыйммәтләрен формалаштыруга; социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр санын киметүгә; ата-ана хокукыннан мәхрүм итү очракларын киметүгә, «риск төркеменә» керүче гаиләләрне ачыклауга, аларны социаль яктан тәэмин итүгә һәм реабилитацияләүгә, гаиләләрдә балалар белән рәхимсез мөгамәлә очракларын киметүгә, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар санын киметүгә ярдәм итә торган нәтиҗәле механизмнар булдыру аеруча актуаль булып тора.

Муниципаль программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары әлеге программаның 2 нче кушымтасында тәкъдим ителгән.

Муниципаль районда әлеге максатларга һәм бурычларга ирешү 3 ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырылачак:

1. 2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр»;
2. 2021 – 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту»;
3. 2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит».

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2021 – 2023 еллар.

## III. Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 108189,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча: 2021 ел – 35148,8 мең сум, 2022 ел – 36051,3 мең сум, 2023 ел – 36989,8 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаны ресурслар белән тәэмин итү буенча җентекле мәгълүмат әлеге программаның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның дәүләт заказчысы – координаторы – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты. Программаны башкаручылар:
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе;
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;
- Кукмара җирле инвалидлар иҗтимагый оешмасы;
- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;
- «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ;
- «Кукмара РҮХ» ДАССУ;
- «Чиста шәһәр» ҖЧҖ;
- Җирлек башлыклары

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Программаны башкаручылар белән берлектә, Программаны тормышка ашыру барышында уртак эшчәнлекне координацияләүне, кирәк булганда аңа үзгәрешләр кертүне, шулай ук Программаның нәтиҗәлелеген бәяләүне, чираттагы финанс елына бюджет ихтыяҗын формалаштыруны тәэмин итә.

Программаны башкаручылар Башкарма комитетка Программа чараларын тормышка ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук «Кукмара муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 27 маендагы 238 номерлы карары нигезендә финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат тапшыралар.

## V. Программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

2023 елга кадәр Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеше Стратегиясенең төп өстенлекләреннән берсе итеп халыкның тормыш шартларын һәм социаль мохит сыйфатын яхшырту билгеләнгән, шуңа күрә Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре муниципаль районның стратегик максатларына ирешүдә зур әһәмияткә ия.

Бу юнәлешләр буенча үткәрелә торган чаралар, социаль юнәлештәге башка чаралар белән беррәттән, кайбер төп бурычларны – халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын эзлекле күтәрү, керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменә җиткән яисә аларга социаль ярдәм чаралары

күрсәтү, шул исәптән дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хисабына аны узып киткән гражданнар санын арттыру мәсьәләләрен хәл итүгә ярдәм итәчәк.

Халыкка күрсәтелә торган адреслы социаль ярдәмне көчәйтү җәмгыятьтә социаль климатны яхшыртырга, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге бюджет акчаларын нәтиҗәлерәк файдаланырга мөмкинлек бирәчәк.

Балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру һәр гаиләнең, бигрәк тә күпбалалы гаиләнең керемен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

1 нче кушымта

«2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, процентлар |
|---|---|---|
| Муниципаль районның аерым категория гражданнарының яшәү сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чараларына хокукларын тәэмин итү | Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга тулы күләмдә түләүсез туклану бирү |
| | | Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә тулы күләмдә компенсация бирү |
| | | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның барлык рәвешләрендә бер тапкыр бирелә торган пособиене тулы күләмдә бирү |
| | | Тәрбиягә алган гаиләгә балаларны карап тоту өчен тулы күләмдә түләү бирү |
| | | Тәрбиягә бала алган гаиләгә балаларны карап тотуга тулы күләмдә акча бирү |
| | | Опекуннарның гаиләләренә балаларны карап тотуга тулы күләмдә акча бирү |
| | | Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының опека һәм попечительлек органнарында оргтехника паркын яңарту |
| | | Ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өлеше |
| | Муниципаль районда инвалидлар һәм башка халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеген арттыру | Өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм башка халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңайлы инфраструктура объектлары өлеше |
| | | Әлеге категориядәге халыкның гомуми исәбендә даими рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | Җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка халыкның  аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру | Сорашулар үткәрелгән инвалидларның гомуми исәбендә халыкның инвалидлар проблемаларына мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлеш |

2 нче кушымта

«2021– 2023 елларга Кукмара муниципаль районы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| Ярдәмче программаның исеме | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мен | |
|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел |
| 2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр» | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты | 5485,8 | 5705,2 |
| 2021– 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты | 29277,5 | 29960,6 |
| 2021– 2023 елларга «Уңайлы мохит» | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты | 385,5 | 385,5 |
| Программа буенча барлыгы еллар буенча | | **35148,8** | **36051,3** |
| Программа буенча барлыгы | | | **108189,9** |

## «2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы

## Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – координаторы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаның төп башкаручылары | - Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе;<br>- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;<br>- Кукмара җирле инвалидлар иҗтимагый оешмасы;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>- «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ;<br>- «Кукмара РҮХ» ДАССУ;<br>- «Чиста шәһәр» ҖЧҖ;<br>- Җирлек башлыклары |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы Кумара муниципаль районында инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре (мөстәкыйль хәрәкәт иткәндә, хезмәтләр алганда, кирәкле мәгълүмат алуда кыенлыклар кичерүче кешеләр) (алга таба – МГН) эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалануны (алга таба – тоткарлыксыз файдаланырлык) тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГН тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемлелеген арттыру; |

<table>
<tr><td></td><td>2) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җәмгыятьтәге социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркем кешеләре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру;</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2021 – 2023 еллар</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре</td><td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1156,5 мең сум тәшкил итә<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Гомуми күләме</th></tr>
<tr><td>2021</td><td>385,5</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>385,5</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>385,5</td></tr>
</table>
Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның еллар буенча бүленгән көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td><td>Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2023 ел ахырына кадәр түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>- сорашулар үткәрелгән инвалидларның гомуми исәбендә халыкның инвалидлар проблемаларына мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 56,8% ка кадәр;<br>- өстенлекле объектларының гомуми санында инвалидлар һәм башка МГН нар өчен өстенлекле социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өлешен 55% ка кадәр;<br>- физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче 6 яштән 18 яшькә кадәр булган физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның 15% ына кадәр;</td></tr>
</table>

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең характеристикасы, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы халкының социаль-демографик структурасы үзенчәлеге инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркеменең халыкның гомуми санына карата чагыштырмача күп булуында чагылыш таба. Хәзерге вакытта районда 5 мең 760 инвалид яши, шуларның 225 е – балалар. Кан әйләнеше системасы авырулары, онкология авырулары һәм сөяк-мускул системасы авырулары белән бәйле инвалидлык югары дәрәҗәдә күзәтелә. Фактта муниципаль районда яшәүче һәр 7 нче кеше – инвалид.

Бу инвалидлар тормышында барлыкка килә торган проблемаларның масштаблылыгын күрсәтә һәм инвалидларны социаль яклау системасын камилләштерү буенча инвалидларны җәмгыятькә интеграцияләүне тәэмин итә торган чаралар комплексын кабул итү кирәклеген билгели.

Соңгы берничә елда районда инвалидларның социаль хәлен яхшыртуга, керемнәрне һәм тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән социаль яклау буенча эш эзлекле алып барыла. Бу система, гомумән алганда, инвалидларның тернәкләндерүгә булган ихтыяҗларын тәэмин итә. Әмма хәзерге көнгә кадәр районда инвалидларга социаль һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, җәмәгать һәм җитештерү биналарына тоткарлыксыз үтеп керү өчен шартлар тулысынча тудырылмаган.

Районда аз хәрәкәтләнүче дүрт категория инвалид – 391 кеше аеруча ярдәмгә мохтаҗ:

-инвалид балалар – 51:

- терәк-хәрәкәт аппараты зәгыйфь булган инвалидлар, шул исәптән 111 кресло-коляскада хәрәкәт итүче инвалидлар, шул исәптән 32 бала,
- ишетү сәләте зәгыйфь булган инвалидлар – 65, шул исәптән балалар – 5,

– күрү сәләте зәгыйфь булган инвалидлар – 164, шул исәптән балалар – 14.

Инвалидлар көн саен күп төрле проблемалар белән очраша, чөнки җәмәгать тормышында тулы хокуклы катнашуларына каршы килә торган җәмгыятьтәге социаль һәм физик киртәләр аркасында тулы тормыш рәвеше алып бара алмыйлар. Инвалидларның тормыш эшчәнлеге мохитенә керүе проблемасының чишелмәгәнлеге берничә җитди социаль-икътисади нәтиҗә тудыра. Алар арасында эш белән тәэмин итүгә, белем һәм культура дәрәҗәсенә, аларның тормыш дәрәҗәсенә һәм сыйфатына тискәре йогынты ясый торган инвалидларның хезмәт һәм социаль активлыгын дестимуляцияләү күзәтелә.

Программаны үтәүнең бөтен чоры дәвамында инвалидларның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү, инвалидларның социаль инфраструктура объектларына һәм мәгълүматка киртәләрсез үтеп керүен тәэмин итү, инвалидларны һөнәри әзерләү һәм эшкә урнаштыру, инвалидларның интеллектуаль һәм мәдәни ихтыяҗларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру чаралары гамәлгә ашачак.

Социаль мохиткә уңышлы җайлашырга, иҗтимагый файдалы хезмәт белән шөгыльләнергә һәм үзләрен җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзалары итеп хис итәргә мөмкинлек бирә торган инвалидларны социаль адаптацияләү тернәкләндерү чараларының ахыргы максаты булырга тиеш.

Бу проблеманы хәл итү бары тик халыкны социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау, мәдәният, мәшгульлек, спорт, мәгариф, инвалидларның иҗтимагый оешмалары катнашында инвалидларны өзлексез тернәкләндерүнең бердәм системасын эшләү һәм тормышка ашыруда комплекслы хәлителергә мөмкин.

Халыкның әлеге категориясенең гомуми санында 2020 елда физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлеше 756 кеше тәшкил итә, шулардан:

Гомуми авыру буенча инвалид булган 652 – кеше;
интеллектуаль җитешсезлекләр белән 53 – кеше ;
күрү сәләте бозылган 14 – кеше;
ишетү сәләте бозылган 5 – кеше;
терәк-хәрәкәт аппараты бозылган 32 – кеше.

Муниципаль районда мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Шәфкать» тернәкләндерү үзәге эшли, аның эшчәнлеге «Инвалидларга, мөмкинлекләре чикләнгән затларга, социаль куркыныч хәлдә калган гаиләләргә һәм балаларга, авыр тормыш хәленә юлыккан һәм стационар, ярымстационар һәм стационар булмаган социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булган башка гражданнарга һөнәри, социаль, психологик реабилитацияләүдә ярдәмне үз эченә алган тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү» дәүләт хезмәте сыйфаты Стандарты нигезендә оештырыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 21 ноябрендәге 1016 номерлы карары белән расланган).

Районда 5 ел дәвамында медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлегенең югары күрсәткечләре сакланды, авыл торак пунктларында сәламәтлек саклау дәрәҗәсе

күтәрелде. Зур Сәрдек, Олыяз, Түбән Комар, Сәрдекбаш, Аш-Буҗи авылларында яңа ФАПлар ачылды. Нырья, Чишмәбаш, Югары Комар, Село Чура авылы ФАПларын, Нырты табиблык амбулаториясен, Лубян участок хастаханәсен капиталь ремонтлау планлаштырыла. Пчеловод ФАПы һәм Ядегәр табиблык амбулаториясе биналары тәмамлану стадиясендә.

Төрле дәрәҗәдәге бюджетлардан финанслау күләме ел саен арта бару ярдәмендә күрелгән чараларга карамастан, мөһим социаль бурыч – физик, икътисади һәм мәдәни даирәдә, сәламәтлек саклау һәм мәгариф, мәгълүмат һәм элемтәдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү юлы белән җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә инвалидлар өчен тигез мөмкинлекләр булдыру – хәл ителмәгән булып кала бирә. Социологик сорашып белешүләр нәтиҗәләре буенча, республиканың сорашуда катнашкан мөмкинлекләре чикле затларының 52 проценты, инвалидлар проблемасына игътибар артуга карамастан, җирле үзидарә органнары тарафыннан уңайлы мохит формалаштыру буенча күрелә торган көчләрнең нәтиҗәлелеген канәгатьләнмәслек дип бәялиләр.

Муниципаль районда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне һәм инвалидларны җәлеп итү буенча эш 9 оешмада алып барыла, аларда 5 белгеч эшли.

830 инвалид армспорт, бадминтон, дартст, җиңел атлетика, чаңгы ярышлары, мини-футбол, өстәл теннисы, пауэрлифтинг, пуля белән ату, йөзү, спорт ориентлашуы, спорт туризмы, футзал, шахмат, шашка, футбол, коляскада бию һәм башка инвалидларның спорт төрләренә керми торган спорт төрләре (спорт дисциплиналары) белән шөгыльләнә.

Инвалидларны тернәкләндерү һәм аларга тормышта башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләр булдыру буенча чаралар планын үтәү кысаларында Ветераннар советы һәм Социаль яклау бүлеге белән берлектә мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен район ярышлары үткәрелә.

Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларда һәм инвалидларда шөгыльләнүгә ихтыяҗ формалаштыру буенча чаралар комплексы кабул итү таләп ителә:

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен гамәлдәге физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт объектларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;
- әлеге категория затлар белән физкультура-реабилитация һәм спорт эшләре өчен белгечләр әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү;

- бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларның һәм инвалидларның катнашуын тәэмин итү;

- мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен адаптив спорт үзәге булдыру.

Моның нәтиҗәсе физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп ителгән физик мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар саны арту булырга тиеш.

Программа социаль характерда һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән берничә өстәмә чараны күздә тота. Ярдәмче программа муниципаль районда, республикада инвалидларны җәмгыятькә интеграцияләү һәм реабилитацияләү өчен шартлар тудыру буенча үткәрелә торган комплексы чараларның дәвамы булырга, инвалидларга һәм башка МГН нарга караган социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итәргә, аларның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрергә тиеш. Ярдәмче программа кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар социаль һәм транспорт инфраструктурасының уңайлы һәркем файдаланырлык объектларын булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Ярдәмче программа «Инвалидлар хокуклары турында» конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 1 пунктын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын арттыру буенча чараларны (юл картасын) раслау турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 716 номерлы Карарын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде. Әлеге ярдәмче программа Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы инвалидларына мәгариф, мәдәният өлкәсендә объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләрен арттыруга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

Подпрограмманың максаты – муниципаль районда инвалидлар һәм башка МГНнар (мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт иткәндә, хезмәт күрсәтүләрдән, кирәкле мәгълүмат алуда кыенлыклар кичерүче кешеләр) тормышының өстенлекле

өлкәләрендә өстенлекле объектларга һәм хезмәтләргә тоткарлыксыз үтеп керүне тәэмин итү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

1) муниципаль районда инвалидлар һәм башка МГН тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемлелеген арттыру;

2) муниципаль районда инвалидларны реабилитацияләү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик һәм кадрлар белән тәэмин итү;

3) җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркем кешеләре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру.

Ярдәмче программаның гамәлгә ашырылуын характерлаучы төп күрсәткечләр:

- тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуын уңай бәяләүче инвалидлар өлеше, муниципаль районда инвалидларның гомуми саны буенча;

- муниципаль районадагы өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңайлы инфраструктура объектлары өлеше;

- һөнәри белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалидларны һәм үсеше бозылмаган затларны бергәләп укытуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган универсаль киртәләрсез мохит формалаштырылган профессиональ белем бирү оешмалары өлеше;

- әлеге категориядәге халык санында физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәр булган физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлеше;

- муниципаль районда сорашып белешүдә катнашкан инвалидларның гомуми санында халыкның инвалидлар проблемаларына мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлеше.

- бу өлкәдә эшләүче белгечләрнең гомуми санында инвалидларны реабилитацияләү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча белем алган һәм квалификацияләрен күтәргән белгечләр өлеше.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында муниципаль районда муниципаль районда инвалидлар һәм башка МГН тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемлелеген арттыруга юнәлдерелгән түбәндәге чаралар каралган:

- җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңү һәм инвалидлар проблемаларына һәм муниципаль районда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркем кешеләре өчен уңайлы тормыш мохитен тәэмин итү проблемасына уңай караш формалаштыру;

- муниципаль районда инвалидлар һәм башка МГНнар өчен уңайлы мохитнең тотрыклы үсеше шартларын формалаштыру;

- муниципаль районда инвалидлар һәм башка МГНнар эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә үтемлелек шартларын формалаштырганда дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлеген һәм эшләрен координацияләүне тәэмин итү;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштыру максатыннан Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГНнар тормышы эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә социаль инфраструктура объектларының һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуы турында мәгълүмат җыю һәм системалаштыру;

- инвалидлар һәм башка МГНнар өчен пассажир, шул исәптән җир өсте транспортының төп төрләренең күчмә составы үтемлелеген тәэмин итү, башка МГНнар өчен уңайлы шартлар формалаштыру.

Подпрограмманы тормышка ашыру вакыты: 2021 – 2023 еллар.
Ярдәмче программаның чаралар исемлеге Ярдәмче программага 1 нче кушымтада, Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары 2 нче кушымтада бирелгән.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1156,5 мең сум тәшкил итә

(мең сум)

| Ел | Гомуми күләме |
|---|---|
| 2021 | 385,5 |
| 2022 | 385,5 |
| 2023 | 385,5 |

Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру механизмы планлаштыру һәм фаразлауны, программа чараларын тормышка ашыруны, Программаны үтәү барышын мониторинглау һәм контрольдә тотуны, программа чараларын, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын, максатчан индикаторларны төгәлләштерү һәм төзәтүне үз эченә ала.

Программа чараларын тормышка ашыру буенча эшләрне башкаручыларны сайлап алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программа кысаларында идарә карарларын кабул итү Программаны башкаручылардан кергән мәгълүматны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- Программаны тормышка ашыру буенча гомуми җитәкчелек итә;
- аны тормышка ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларны раслый;
- Программа чараларын тормышка ашыру өчен, шулай ук аның тарафыннан финанс йөкләмәләрен үтәү турында, шул исәптән Программа чараларын гамәлгә ашыруны күздә тоткан программаларны һәм (яки) муниципаль программаларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) җирле бюджетлар чыгымнары турында, Программаның максатчан күрсәткечләренең ирешелгән кыйммәтләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә уңайлы мохит формалаштыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында хисап бирү өчен җаваплы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы билгели;
- субсидияләрнең максатчан, адреслы һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тота.

Муниципаль заказчы – Программаның координаторы һәм төп эшләүчесе аны тормышка ашыру барышында:

- Программаны тормышка ашыру белән җитәкчелек итә һәм агымдагы идарәне гамәлгә ашыра;
- Программаның барлык башкаручылары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, инвалидларның иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген координацияли;
- Программаның нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итә;
- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә һәм тиешле контрактлар төзүгә заказлар урнаштыруны контрольдә тота;

- үз компетенциясе кысаларында аны тормышка ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актлар эшли;
- Программаны тормышка ашыруның барышы турында квартал саен хисап алып баруны гамәлгә ашыра;
- Программаны тормышка ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында ел саен доклад әзерли;
- Программаны тормышка ашыру барышы һәм нәтиҗәләре турында электрон рәвештә мәгълүмат урнаштыруны оештыра;
- Программаны гамәлгә ашыру барышын яктырту мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту һәм бәяләү өчен, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору буенча Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда катнашучы Башкарма хакимият органнары һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән торган эшче төркем төзелә (алга таба – Эшче төркем).

Эшче төркем Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда ярдәм итүче контрольлек итүче орган булып тора, һәм дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль район, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру белән бәйле башка органнар һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыра.

Эшче төркемнең төп бурычлары:

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, муниципаль район, республиканың башка органнары һәм оешмалары тәкъдимнәре буенча карарлар кабул итү;

эшләр торышын анализлау һәм Ярдәмче программаны үтәү механизмнарын куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлешендә региональ законнарны камилләштерү буенча карарлар кабул итү;

Ярдәмче программа чараларын, шул исәптән норматив хокукый, методик характердагы чараларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен үтемлелек өлешендә законнарның үтәлешен мониторинглау системасын контрольдә тоту;

Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә муниципаль заказчысы – Ярдәмче программа координаторыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, муниципаль районның, республиканың җирле үзидарә органнарыннан, башка органнардан һәм оешмалардан кирәкле материалларны соратып алырга;

Ярдәмче программа чараларын алга таба гамәлгә ашыру өчен нәтиҗәләр ясарга һәм тәкъдимнәр әзерләргә.

Эшче төркем Эшче төркем җитәкчесе, аның урынбасары, секретарь һәм Эшче төркем әгъзалары составында формалаша, алар төркем эшендә катнаша.

Эшче төркем утырышларын әзерләү һәм оештыру, Эшче төркем эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итүне Эшче төркем секретаре башкара.

Эшче төркем утырышлары аена кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта, Эшче төркемнең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Эшче төркем составы муниципаль район Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## V.Ярдәмче программаның социаль һәм икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре:

1) Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГНнар өчен уңайлы мохитнең тотрыклы үсеше шартларын формалаштыру;

2) Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГНнар эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә үтемлелек шартларын формалаштырганда дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлеген һәм эшләрен координацияләүне тәэмин итү;

3) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштыру максатыннан Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГНнар тормышы эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә социаль инфраструктура объектларының һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуы турында мәгълүмат җыю һәм системалаштыру;

4) инвалидлар һәм башка МГНнар тормышының өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге шартларын формалаштыру;

5) Кукмара муниципаль районында инвалидлар һәм башка МГНнар өчен пассажир транспортының төп төрләренең күчмә составы үтемлелеген тәэмин итү;

6) Кукмара муниципаль районында инвалидлар өчен реабилитация хезмәтләренең үтемлелеген һәм сыйфатын арттыру;

Ярдәмче программаның норматив хокукый, методик характердагы чараларын гамәлгә ашыру, инвалидлар һәм башка МГНнар өчен яңадан төзелә торган социаль инфраструктура объектларының үтемлелек өлешендә законнар үтәлешен

мониторинглау һәм контрольдә тоту системасын булдыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

муниципаль районда инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен эзлекле рәвештә киртәләрсез мохит булдыруны тәэмин итәргә;

Ярдәмче программаның гамәли чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

Инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү;

инвалидларның социаль бәйлелеген киметү һәм изоляцияне җиңү;

инвалидларның социаль һәм хезмәт активлыгын стимуллаштыру;

Инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренең тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге объектладан һәм хезмәтләрдән файдалана алуына.

«2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасына 1 нче кушымта

**«2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы чаралары исемлеге**

| № | Чаралар исеме | Норматив хокукый акт, чара үткәрү каралган башка документ | Җаваплы башкаручылар, бергә башкаручылар | Тормышка ашыру вакыты | Чараның инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеге күрсәткечләренең әһәмиятен күтәрүгә йогынты ясавының планлаштырылган нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| **1 бүлек Норматив базаны камилләштерү** | | | | | |
| 1.1. | Социаль инфраструктура объектларының һәркем файдаланырлык булуына мониторинг үткәрү | | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | 2021 – 2023 еллар | Юкка чыгару максаты белән, үтемлелек таләпләрне бозу очракларын ачыклау |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.2 | Социаль инфраструктура объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә проектларны инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен яраклылык предметына килештерү. | РДС35-201-99 «Инвалидлар өчен социаль инфраструктура объектларына керү мөмкинлеге таләпләрен гамәлгә ашыру тәртибе» | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (инфраструктура үсеше бүлеге) | даими | Социаль инфраструктура объектларының һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү |
| 1.3 | Районның социаль инфраструктура объектларын гамәлгә керткәндә яисә реконструкцияләгәндә объектлар милекчеләренең шәхси мөрәҗәгате буенча тикшерү, объектларның инвалидлар өчен үтемлелек таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү | РДС35-201-99 «Инвалидлар өчен социаль инфраструктура объектларына керү мөмкинлеге таләпләрен гамәлгә ашыру тәртибе» | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге<br>Кукмара | 2021 – 2023 еллар | Районның элементлар белән җиһазландыруга мохтаҗ булган социаль инфраструктура объектларын ачыклау |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | муниципаль районы Башкарма комитеты (инфраструктура үсеше бүлеге) | | |
| 1.4 | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына инвалидлар өчен үтемлелек шартларын тәэмин итүгә таләпләр кертү | 2014 елның 01 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 ел | Инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү |
| 1.5 | Инвалидлар ихтыяҗлары өчен гамәлдәге объектларны тулысынча яраклаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, хезмәтләрне дистанцион рәвештә яки өйдә күрсәтү турында нигезләмәләр эшләргә кирәк | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы РФ ФЗның 15 статьясы | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2022 ел | Инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү |
| **II бүлек<br>Кирәкле җайланмалар белән объектларны җиһазлауны да кертеп, инвалидлар өчен инфраструктура** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **объектларының (транспорт чаралары, элемтә чаралары һәм мәгълүмат чаралары) үтемлелеге күрсәткечләре кыйммәтен этаплап арттыру буенча чаралар** | | | | | |
| 2.1 | Биналарны яраклаштыру:<br>«Манзарас урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ,<br>- «Кукмара 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ,<br>- «Кукмара штп Ч. Айтматов ис. 1 нче гимназисе» МБГББУ,<br>«Ялкын» яшүсмерләр клубы<br>- ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Инвалидларның һәм башка МГНнарның, аларның махсус ихтыяҗларын исәпкә алып, тоткарлыксыз керә алуы өчен һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен:<br>1. Пандуслар урнаштыру;<br>2. Керү төркемен яраклаштыру;<br>3. Инвалид автотранспорты өчен парковка урыны булган керү мәйданын төзекләндерү;<br>3. Санитар-гигиена биналарын яраклаштыру. | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 19 маендагы 358 номерлы ТР МК карары | Кукмара МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Яшьләр һәм спорт идарәсе, Кукмара МР Башкарма комитеты | 2021 – 2023 еллар | Әлеге объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең (мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт иткәндә, хезмәтләр алганда, кирәкле мәгълүмат алуда кыенлыклар кичерүче кешеләргә) тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителәчәк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | «2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы | | | |
| 2.2 | Кукмара шәһәрендә инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре өчен җәяүлеләр чыгу урыннарын җайлаштыру | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның | Кукмара МР Кукмара ш.т. п. Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» ҖЧҖ; | 2021 – 2023 еллар | Кукмара муниципаль берәмлегендә автомобиль юллары чикләрендә инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренең хәрәкәтенең тоткарлыксыз булуын һәм иминлеген тәэмин итү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 19 маендагы 358 номерлы ТР МК карары 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы | | | |
| 2.3 | Кукмара шәһәре транспорт һәм урам-юл челтәрен инвалидларга социаль әһәмияткә ия объектларга тоткарлыксыз үтеп керү өчен яраклаштыру (6.4 «Машина кую урыны» һәм 8.17 «Инвалидлар» юл тамгаларын урнаштыру) | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның | Кукмара МР Кукмара ш.т. п. Башкарма комитеты, «Чиста шәһәр» ҖЧҖ | 2021 – 2023 еллар | Әлеге объектка һәм хезмәтләргә инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре өчен тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тудырылачак. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 19 маендагы 358 номерлы ТР МК карары 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы | | | |
| 2.4 | Инвалидлар өчен «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ биналарының инвалидлар өчен уңайлылыгын арттыру максатыннан яраклаштыру | «Уңайлы мохит» программасы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Санитар-гигиена биналарын яраклаштыру<br>Керү төркемен яраклаштыру<br>Биналар эчендә хәрәкәт итү юлларын яраклаштыру<br>Территорияләрне яраклаштыру |
| 2.5 | Авыл мәдәният йортларын инвалидлар өчен яраклаштыру. | «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы, «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Мәдәният объектының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуы |
| **III бүлек**<br>**Инвалидларга, аларда булган организмның бозылган функцияләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләрдән** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **файдалану мөмкинлеге күрсәткече кыйммәтен этаплап арттыру буенча чаралар, шулай ук объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда аларга ярдәм күрсәтү.** | | | | | |
| 3.1 | Кукмара халыкны эш белән тәэмин итү үзәге аша инвалидларны эшкә урнаштыру | «Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча РФ аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 419 номерлы Федераль закон | «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | Даими | Инвалидларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү |
| 3.2 | Бушлай (1,2 төркем инвалидлары өчен), ташламалы (3 төркем инвалидлары өчен) музейга бару | «Мәдәният турында» «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектының 17 статьясы | «Кукмара муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» МБУ | Даими | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру, конституцион хокукларны гамәлгә ашыру һәм аларның җәмгыятьтә интеграцияләнүен тизләтү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.3 | Кукмара мәдәният йортында мәдәни-күңел ачу чарасына инвалидлар өчен 10 утыру урыны бүлеп бирү | «Мәдәният турында» «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектының 17 статьясы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | Даими | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру, конституцион хокукларны гамәлгә ашыру һәм аларның җәмгыятьтә интеграцияләнүен тизләтү |
| 3.4 | Районның социаль учреждениеләре базасында өлкән инвалидлар һәм инвалид балалар өчен сабантуйлар оештыру һәм үткәрү | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге башлыгы тарафыннан ел саен раслана торган социаль яклау учреждениеләренең чаралар планы | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау учреждениеләре | ел саен | Инвалидлар өчен спорт-ярыш һәм мәдәни-күңел ачу чаралары |
| 3.5 | Инвалидлар декадасын үткәрү кысаларында чаралар оештыру | Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан ел саен раслана торган чаралар планы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | ел саен | Инвалидлар проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, аларга ярдәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәтү һәм булышу максатларында чаралар |
| 3.6 | Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен Тернәкләндерү үзәгендә чаралар оештыру:<br>- Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән берлектә инвалид балалар өчен җәйге хезмәт лагере оештыру;<br>- инвалид балаларның ата-аналары өчен гамәли иҗат буенча мастер-класслар, йомгаклау күргәзмәләре һәм инвалид балалар кул эшләнмәләре күргәзмәләре оештыру һ. б. | «Шәфкать» реабилитация үзәгенең ел саен реабилитация үзәге директоры тарафыннан раслана торган чаралар планы | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара МР социаль яклау бүлеге | ел саен | Инвалид балалар һәм еш авыручы балалар өчен тернәкләндерү чаралары үткәрү |
| 3.7 | «Тылсым» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге күчмә бригадасының хәрәкәттә проблемалары булган инвалидларның өенә барып эшләве | «Тылсым» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге нигезләмәсе | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль | Даими | Район инвалидларына медицина реабилитациясе, психологик ярдәм күрсәтү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | районындагы Социаль яклау бүлеге | | |
| 3.8 | Бушлай ксерокопия ясау, мәгълүматны электрон йөртүчеләргә күчерү, уку залыннан китаплар бирү, Интернеттан файдалану | «Мәдәният турында» «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектының 17 статьясы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | Даими | Мәгълүмати тигезсезлекне бетерү, шәһәр халкының, шул исәптән инвалидларның да, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне куллану мөмкинлеген тәэмин итү |
| 3.9 | Инвалидлар өчен һәм алар катнашында мәдәни-күңел ачу, танып-белү чаралары һәм концерт программалары оештыру һәм үткәрү | «Мәдәният турында» «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектының 17 статьясы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру, конституцион хокукларны гамәлгә ашыру һәм аларның җәмгыятьтә интеграцияләнүен тизләтү. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең иҗади |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | казанышларын һәм талантларын күрсәтү |
| 3.10 | «Зилант» Спорт мәктәбе»ндә инвалид балалар белән уку-тренировка дәресләре | «Зилант» Спорт мәктәбе» Уставы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | ел дәвамы нда | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең спорт казанышларын күрсәтү |
| 3.11 | «Аргамак» спорт командасының төрле категория инвалидлар (балалар һәм өлкәннәр) арасында спортның төрле төрләре буенча ТР беренчелекләрендә һәм чемпионатларында катнашуы | ТР инвалидларының физкультура-спорт җәмгыятенең спорт чараларының календарь планы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | Ел дәвамы нда | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең спорт казанышларын күрсәтү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.12 | Инвалидлар арасында өстәл уеннары буенча Спартакиада үткәрү. | ТР Кукмара МР Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенең спорт чаралары календарь планы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | Инвалидлар декадасы кысаларында | Инвалидлар өчен тернәкләндерү чаралары күләмен арттыру. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең спорт казанышларын күрсәтү |
| 3.13 | Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрне укыту | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү буенча дәүләт программасы | «Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | 2021 – 2023 еллар | Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү урынына инвалидлар өчен уңайлы мохит булдыру |
| **IV бүлек<br>Инвалидлар белән эшләүче белгечләрне инвалидлар өчен объектларның, хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итүгә һәм аларны куллануда яки алуда (аннан файдалану мөмкинлегендә) ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **буенча укыту яки инструкция чаралары.** | | | | | |
| 4.1 | Белгечләрне сурдотәрҗемә буенча укырга җибәрү. | «Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча РФ аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 419 номерлы Федераль закон | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Ишетү буенча инвалидлар белән аралашырга өйрәтелгән белгечләр саны артачак. Ишетү буенча инвалидларга хезмәт күрсәтү сыйфаты яхшырачак. |
| 4.2 | Инвалидлар өчен объектларның һәм аларга күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалануны мөмкинлеген тәэмин итү, шул ук вакытта кирәкле ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча укыту (инструкцияләү) өчен белгечләр җибәрү | «Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча РФ аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 419 | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге, Кукмара муниципаль районы | 2021 – 2023 еллар. | Инвалидлар белән эшләргә өйрәтелгән белгечләр саны артачак. Инвалидларга хезмәт күрсәтү сыйфаты яхшырачак. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | номерлы Федераль законның 15 статьясы | Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | | |
| 4.3 | Халыкка хезмәт күрсәтүче учреждениеләр хезмәткәрләренә инвалидларга алар өчен аңлаешлы булган форматларда хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча инструкция (укыту) үткәрү.<br>«Олимп спорт мәктәбе» МБУдә инвалидларга хезмәт күрсәтү өчен тренерны укыту кирәклеге. | «Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча РФ аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 419 номерлы Федераль законның 15 статьясы | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау бүлеге<br>Кукмара МР Башкарма комитеты, Советы, Мәгариф, Мәдәният, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе Советы | 2021 – 2023 еллар | Чаңгы базасында инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү. |

«2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасына 2 нче кушымта

## «2021 – 2023 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеге күрсәткече исеме | Үлчә берәм иге |
|---|---|
| 1. 2016 елның 1 июненнән гамәлгә кертелгән халыкка хезмәт күрсәтелә торган социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының, шулай ук халыкны ташу өчен файдаланыла торган, инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеге таләпләренә тулысынча туры килә торган транспорт чараларының чагыштырма күләме (яңадан кертелә торган объектларның һәм халыкны ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының гомуми саныннан) | % лард |
| 2. 2016 елның 1 июненнән соң аларда капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткәрү нәтиҗәсендә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең үтемлелеге таләпләренә тулысынча туры киләторган гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының чагыштырма күләме (капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән объектларның гомуми саныннан). | % лард |
| 3. Инвалидларның шәхси мобильлеге һәм бина буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге шартлары тәэмин ителә торган объектларның чагыштырма күләме (кирәк булганда – объект территориясе буенча) һәм шул исәптән бар:<br>3.1. инвалидлар өчен автотранспорт чаралары өчен бүлеп бирелгән стоянкалар;<br>3.2. җайлаштырылган лифтлар (булганда);<br>3.3. култыксалар (поручни);<br>3.4. пандуслар;<br>3.5. уңайлы керү төркемнәре;<br>36. уңайлы санитар-гигиена бүлмәләре;<br>3.7. стеналардагы ишек уемнарының (проем), баскыч маршлары, мәйданчыкларының җитәрлек киңлеге. | % лард |
| 4. Күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны озату һәм аларга ярдәм күрсәтү тәэмин ителгән объектларның чагыштырма күләме. | % лард |
| 5. Тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, санитар-гигиена нормаларына туры килә торган шартларда эшләүче инвалидлар (эшләүче инвалидларның гомуми саныннан) өлеше | % лард |
| 6. Халыкка хезмәт күрсәтүче һәм инвалидлар белән эшләү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча инструкция яки укулар үткән хезмәткәрләр өлеше (халыкка хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гомуми саныннан). | % лард |
| 7. Инвалидларга объект яки социаль хезмәтләр персоналы озатуында күрсәтелә торган хезмәтләр өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең чагыштырма күләме (күрсәтелә торган хезмәтләрнең гомуми саныннан). | % лард |

| | |
|---|---|
| 8. Инвалидларга хезмәт күрсәткәндә административ-боеру акты белән ярдәм күрсәтү йөкләнгән оешмалар хезмәткәрләре өлеше (халыкка әлеге хезмәтләрне күрсәтүче персоналның гомуми санынннан). | % лард |
| 9. Әлеге өлкәдә объектларның һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеге паспортлары булган объектларның чагыштырма күләме (гомуми саннан) | % лард |
| 10. Өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре өчен уңайлы инфраструктура объектлары өлеше | % лард |
| 11. Әлеге категориядәге халык санында физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәр булган физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлеше | % лард |
| 12. Сорашып белешүдә катнашкан инвалидларның гомуми санында халыкның инвалидлар проблемаларына мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлеше | % лард |

**2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасы**
**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасы |
| Дәүләт заказчысы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны башкаручылар | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, муниципаль белем бирү оешмалары |
| Ярдәмче программаның максаты | Муниципаль районның аерым категория гражданнарының яшәү сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чараларына хокукларын тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | - Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чараларын |

| | |
|---|---|
| | бирү |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021 – 2023 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре | 2021 – 2023 елларда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 17124,4 мең сум тәшкил итә<br><br>Ел / Барлыгы (мең сум):<br>2021 — 5485,8<br>2022 — 5705,2<br>2023 — 5933,4<br><br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның еллар буенча бүленгән көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2023 елга кадәр һәр елны барлык укучыларга да бушлай туклануны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе характеристикасы

Әлеге Ярдәмче программа гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары өчен билгеләнгән вәкаләтләрне үтәү максатларында эшләнгән. Федераль һәм республика законнары нигезендә аларга хокуклы гражданнарның барлык категорияләренә айлык (еллык) социаль түләүләр үз вакытында һәм тулы күләмдә бирелә.

Ярдәмче программа кысаларында аерым категория гражданнарның социаль ярдәм чараларына, аерым алганда, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның барлык категорияләре өчен түләүсез туклануга хокукларын үз вакытында һәм тулы күләмдә тәэмин итүне оештыруга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырылачак.

Туклануны оештыруны камилләштерү хәзерге вакытта балаларның сәламәтлеген саклауны тәэмин итүдә иң актуаль проблемаларның берсе булып тора. Тулы кыйммәтле һәм баланслы туклану авыруларны профилактикалауга, эшкә сәләтлелекне һәм өлгерешне арттыруга, балалар һәм яшүсмерләрнең физик һәм акыл үсешенә ярдәм итә, аларның киләчәк тормышка җайлашуы өчен уңайлы шартлар тудыра.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, мәктәп укучыларының гомуми саныннан 5,7 процентка якыны алиментар-бәйле чирләргә ия (гәүдә массасы җитмәү 1,5 процент укучыда, симерүдән – 1,2 процент, анемиядән – 0,3 процент, ашкайнату органнары авырулары белән – 2,2 процент, тире һәм тире астындагы май күзәнәкләре авырулары белән – 0,4 процент, шикәр диабеты белән 0,1 процент укучы җәфа чигә). Мәктәп укучыларының авырулар саны структурасында сулыш органнары, сөяк-мускул системасы авырулары белән беррәттән ашкайнату органнары авырулары да әйдәп баручы урынны алып тора.

«2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләрнең күләме турында» 2009 елныың 28 августындагы 724 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, 2020 елда уку чорында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклындырган өчен түләү күләме һәркөнне 7 сум 70 тиен тәшкил итте. 2021 елның 1 гыйнварыннан көндәлек түләү 8 сум 00 тиен тәшкил итәчәк.

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин боерыгы буенча, 2020 елда яңа уку елы башыннан республиканың барлык мәктәпләрендә, шул исәптән безнең район мәктәпләрендә 1-4 сыйныф укучыларына 2020 елга бер укучыга – 51,85 сум, 2021 елга – 53,41 сум, 2022 елга – 55,01 сум, 2023 елга – 55,01 сумлык түләүсез кайнар аш оештырылган.

Белем бирү оешмаларында туклануны оештыру «Мәгариф турында» РФ Законы, дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләр составыннан, мондый гаиләләр аз тәэмин ителгән очракта, укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итүне регламентлый торган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын

тукландыруны тәэмин итү турында» 2020 елның 20 октябрендәге 602 номеры Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыруга карата бердәм санитар-эпидемиологик таләпләрне билгеләү максатыннан, гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр (СанПин 2.4.5.5409-08) нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдиме белән 2015 елдан башлап барлык гомуми белем бирү оешмалары өчен бердәм меню эшләнде һәм гамәлгә кертелде.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыруның көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләрен, срокларын һәм этапларын тасвирлау

Подпрограмманың максаты– муниципаль районның аерым категория гражданнарының тормыш итү сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чараларына хокукларын тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен, гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында билгеләнгән социаль ярдәм чаралары бирү карала.

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү бурычын тормышка ашыру кысаларында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итәргә кирәк.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы белешмәләр Ярдәмче программагакушымтада тәкъдим ителгән.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты– 2021 – 2023 еллар.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2021 – 2023 елларда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 17124,4 мең сум тәшкил итә

| Ел | Барлыгы (мең сум) |
|---|---|
| 2021 | 5485,8 |
| 2022 | 5705,2 |
| 2023 | 5933,4 |

Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның муниципаль заказчысы – координаторы булып Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тора. Программаны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, мәктәпкәчә, башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмалар башкара.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе:

чаралар үтәлешен контрольдә тоту;

бүлеп бирелә торган финанс чараларының башкаручылар тарафыннан рациональ кулланылышын контрольдә тоту;

Ярдәмче программа чаралары киселешендә Ярдәмче программаның үтәлеше буенча хисап (квартал, еллык) формалаштыру;

чираттагы финанс елына Ярдәмче программа чараларын ассигнованиеләү өчен җыелма бюджет гаризасын билгеләнгән тәртиптә әзерләү һәм бирү.

Ярдәмче программада каралган чараларны финанслау тәртибе, шулай ук гамәлгә ашыру механизмы федераль һәм республика законнары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән. Ярдәмче программага билгеләнгән тәртиптә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертелә ала.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына квартал саен Ярдәмче программаны тормышка ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук, билгеләнгән формаларны тутырып, финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшыра.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Бу юнәлешләр буенча үткәрелә торган чаралар, социаль юнәлештәге башка чаралар белән беррәттән, кайбер төп бурычларны – халыкның тормыш

дәрәҗәсен һәм сыйфатын эзлекле күтәрү, балалары булган гаиләләрнең керемнәрен арттыру, керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменә җиткән яисә аларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү, шул исәптән дәүләт социаль ярдәме күрсәтү хисабына аны узып киткән гражданнар санын арттыру мәсьәләләрен хәл итүгә ярдәм итәчәк.

2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасына 1 нче кушымта

2021 – 2023 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, процентлар | Еллар буенча индикаторларның кыйммәте, % ларда | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| Социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру һәм социаль хезмәтләр күрсәтү, шулай ук аерым категорияләрдәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү. | Муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә тормыш сыйфатын күтәрү һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга бушлай туклану бирү | 100 | 100 | 100 |

**2021– 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасы ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2021 – 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Подпрограмманың муниципаль заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп | Башкарма комитет, Опека һәм попечительлек бүлеге, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының |

<table>
<tr><td>эшләүчеләр</td><td>Мәгариф идарәсе</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның максаты</td><td>- Гаиләгә һәм гаилә кыйммәтләренә ярдәм итү, ныгыту һәм яклау, гаилә тормышының сыйфатын күтәрү;<br>- Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру;</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның бурычлары</td><td>Түбәндәге өлешләрдә муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү:<br>- муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү;<br>- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация бирү;<br>- гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары системасын үстерү;<br>- ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру;<br>- гаиләдә яшәү рәвешенең кыйммәтен һәм иҗтимагый абруен күтәрү, җаваплы ата һәм ана булуны пропагандалау;<br>- гаилә иминлеге, балалар күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау.</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2021 – 2023 еллар</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләмнәре</td><td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 89 909,0 мең сум тәшкил итә<br><table><tr><td>2021 ел</td><td>29277,5 мең сум</td></tr><tr><td>2022 ел.</td><td>29 960,6 мең сум</td></tr><tr><td>2023 ел.</td><td>30 670,9 мең сум</td></tr></table>Ярдәмче программаны финанслау күләме алдан фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның еллар буенча бүленгән көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- Үз вакытында тулы күләмдә бирүне тәэмин итәргә:<br>- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү;<br>- тәрбиягә бала алган гаиләгә балаларны карау өчен вознаграждение билгеләү;<br>- тәрбиягә бала алган гаиләгә балаларны карап тотуга түләү билгеләү;<br>- опекуннарның гаиләләренә балаларны карап тотуга түләү билгеләү;<br>- муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органында оргтехника паркын 100 процент дәрәҗәсендә яңартуны тәэмин итү;<br>- район гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өлешен 98,8 процентка кадәр арттыру;<br>- тулы күләмдә бирүне тәэмин итәргә<br>- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләр |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының характеристикасы.

Ярдәмче программа Россия җәмгыятенең фундаменталь нигезе буларак гаиләне ныгытуга һәм яклауга, җәмгыять тормышында гаиләнең ролен арттыруга, гаилә уңышсызлыгын кисәтү һәм булдырмауга, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән. Муниципаль районда балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары федераль һәм республика законнары нигезендә күрсәтелә.

Гаилә бала өчен төп тулы кыйммәтле үсеш факторы булып тора. Бала хокукларын тормышка ашыру максатыннан районда максатчан эш алып барыла, шул исәптән:

ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны үз вакытында ачыклау һәм аларны урнаштыру;

суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган һәм чикләнгән сәләтле затларны опекага урнаштыру;

опекадагы (тәрбиягә алган) балаларны карау өчен бер тапкыр бирелә торган пособиене, айлык акчалата түләүләрне үз вакытында билгеләү, тәрбиягә алган ата-аналарга вознаграждение;

социаль гарантияләр бирүнең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар күрелә.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенең балигъ булмаганнарның, шул исәптән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, шулай ук суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган һәм чикләнгән сәләтле затларның шәхси, мөлкәти булмаган һәм мөлкәти хокукларын яклау буенча эшчәнлеге Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Гаилә кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексы, Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексы, «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Федераль законы,федераль дәрәҗәдә һәм Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә кабул ителгән һәм опека һәм попечительлек мәсьәләләрен җайга салучы башка законнар һәм башка норматив хокукый актлар (шул исәптән югарыда күрсәтелгән), шулай укКукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 08.05.2008 елның 08 маендагы 53 номерлы карары белән расланган Опека һәм попечительлек бүлеге турында Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

| Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны урнаштыру буенча мәгълүмат | 01.12.2020 |
|---|---|
| Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны, шул исәптән: | 125 |
| уллыкка алынган | 41 |
| опекага (попечительлеккә) алынган | 41 |
| тәрбиягә алган гаиләләрдә | 43 |
| возмездная опека (суворовчылар) | 0 |

Бүлекнең кадрлар составы – 3 хезмәткәр: бүлек башлыгы, ике баш белгеч. Бүлек хезмәткәрләренең саны, аларның белем дәрәҗәсе һәм эш тәҗрибәсе куелган таләпләргә туры килә.

Опека һәм попечительлек бүлеге эше Кукмара муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе, Социаль яклау бүлеге һәм учреждениеләре, Пенсия фонды идарәсе, ГХАТ бүлеге, мәгариф һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре, авыл җирлекләре башкарма комитетлары һәм башка оешмалар, учреждениеләр һәм ведомстволар белән тыгыз элемтәдә башкарыла.

Балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча мәсьәләләр гаиләләр белән эшләү буенча ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумы утырышларында даими рәвештә тикшерелә һәм карала. Утырыш нәтиҗәләре буенча ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга, балаларның күзәтүсезлегенә юл куймауга юнәлдерелгән тиешле чаралар күрелә.

2020 елның гыйнвар-ноябрь айларында районда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 2 бала ачыкланды, шулардан 1 бала – попечительлеккә, 1се тәрбиягә бала алган гаиләгә тапшырылды.

2020 елда ТР Кукмара район суды тарафыннан 3 баланы район гражданнарының уллыкка алуы турында 3 карар чыгарылды. Элек балалар тәрбиягә алмаштыручы гаиләләргә тапшырылды.

2020 елда 2 бала ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында региональ банкка исәпкә куелган. 2 бала исәптән төшерелде. 2020 елның 1 декабренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында региональ банкта исәптә торучы балалар саны – 2, алар Лубян урман-техник колледжында белем ала һәм тулысынча дәүләт тәэминатында торалар.

Гаиләдә тәрбияләнүче балалар – хисап елы ахырында исәпкә алынган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны районда барлыгы 125 кеше тәшкил итә (шул исәптән 84 е – опекага алынган, 41е – уллыкка алынган).

Опекага алынган 84 баланы карап тоту өчен ай саен укучыга – 10375 сум, мәктәпкәчә яшьтәге балага – 8 997 сум күләмендә акчалата пособие түләнә. Баланы гаиләгә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган түләү күләме бер балага 18 004,12 сум тәшкил итә.

2020 елның 01 декабренә районда 25 тәрбиягә бала алган гаилә исәптә тора, аларда 43 тәрбиягә алынган бала яши. Опека һәм попечительлек буенча вазыйфалары бушлай башкарыла торган гаиләләр саны (тәрбиягә бала алган гаиләләрдән һәм ата-ана гаризасы буенча балалар тәрбияләүче гаиләләрдән тыш) – 34, аларда 41 бала яши. Уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләләр саны – 34, аларда

балалар – 41. 37 бала туендыручысын югалту буенча пенсия ала. Тәрбиягә алынган 6 бала инвалид.

«2016 – 2020 елларга балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны, сукбайлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау» район программасы кысаларында Кукмара районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге, профилактика системасы учреждениеләре белән берлектә, имин булмаган гаиләләргә, шул исәптән районның авыл җирлекләренә дә барып, социаль патронажлар, кичке рейдлар үткәрә. Социаль куркыныч, авыр тормыш хәлендә булган 2 бала (шул исәптән 8 е – ата-аналар гаризасы, балигъ булмаган балаларның шәхси гаризасы буенча, 3 есе – опека һәм попечительлек бүлеге үтенечнамәсе буенча, 1 бала – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә) балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларга вакытлыча урнаштырылды, 2 сабый бала – соңыннан Казан шәһәренең «Республика махсуслаштырылган балалар йорты» ДАССУ га тернәкләндерү дәвалавы үткәрергә җибәрү өчен Кукмара районы үзәк хастаханәсенең балалар бүлегенә урнаштырылды. Аларның 8 е – ата-аналарына, 1 се – тәрбиягә бала алган гаиләгә кайтарылды, хәзерге вакытта 3 се – Алабуга шәһәренең балалар йортында, 2 се – Казан шәһәренең балалар йортында.

Опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең мөһим бурычы – ятим балаларны, ата-ана һәм шулар арасыннан булган затлар тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак биналарының сакланышын ачыклау, исәпкә алу һәм тәэмин итү. Беркетелгән торак мәйданы турындагы белешмәләр, торак урыннардан читләштерүгә юл куймас өчен, даими рәвештә регистрация хезмәтенә тапшырыла.

ООпека һәм попечительлек бүлеге белгечләре опекага алынган балаларның яшәү шартларын даими тикшереп торалар, белем бирү учреждениеләре һәм авыл башкарма комитетлары белән элемтәдә торалар. Хисап чорында 117 балигъ булмаган опекага алынган балага, шул исәптән 5 уллыкка (кызлыкка) алынган балага тикшерү үткәрелгән.

Балигъ булмаганнарның, шулай ук гражданнарның торак һәм милек хокукларын яклау буенча эш алып барыла. Балигъ булмаганнар тарафыннан хезмәткә сәләтсез гражданнарны карауны тормышка ашыру турында 32 рөхсәт бирелде.

2020 елның 1 декабренә опека һәм попечительлек бүлегендә эшкә сәләтсез опека карамагындагы 141 граждан исәптә тора. Эшкә яраксызларның пенсиясен һәм башка социаль түләүләрне тотуны контрольдә тоту буенча эш алып барыла.

Ярдәмче программа кысаларында аерым категория гражданнарның социаль ярдәм чараларына хокукларын үз вакытында һәм тулы күләмдә тәэмин итүне оештыруга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла, аерым алганда:

мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен аата-ана түләве өлешенә компенсацияне бирү;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ата-аналарга ата-аналар түләве өлешенә түбәндәге компенсация түләнә:

беренче бала өчен – мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең уртача күләменең 20 проценты күләмендә;

икенче балага – күрсәтелгән түләү күләменең 50 проценты күләмендә;

өченче балага һәм аннан соңгы балаларга – күрсәтелгән түләү күләменең 70 проценты күләмендә.

2014 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве өлешенә өстәмә компенсация билгеләнгән. Өстәмә компенсация бер кешегә уртача керем аена 20 мең сумнан артмаган гражданнарга бирелә.

Кукмара муниципаль районында һәркем файдаланырлык булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы 54 белем бирү оешмасында, шул исәптән 31 балалар бакчасында һәм мәктәпкәчә төркемнәр белән 23 гомуми белем бирү мәктәбендә гамәлгә ашырыла. 2020 елның 1 сентябренә балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр саны 2627 кеше тәшкил итә, шул исәптән 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр – 2158 кеше. 2013 елның 20 декабрендәге 510 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә инвалид балаларны, ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) түләү алынмый. 30 баланы, шул исәптән 20 инвалид баланы, 1 ятим һәм 9 ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве алынмый. Күп балалы гаиләдән 674 бала ата-ана түләвеннән 50% ка азат ителде. 2009 елның 19 декабрендәге 701 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының карары нигезендә, керемнәре җан башына яшәү минимумыннан түбәнрәк булган өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләр ата-ана түләвеннән 100% ка азат ителде.

Балалар бакчасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве учреждение төренә, эш режимына һәм баланың яшенә бәйле. Балалы гаиләләргә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм

тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен формалаштыруга карашны үзгәртү турында карар кабул итте. Бала балалар бакчасында булмаган чор өчен ата-аналар түләвенең даими өлеше (абонент түләве) киметелде. Әлеге ярдәм чарасы вакыты чикләнмәгән нигездә кертелде. 2020 елда бала 10,5 сәгать була торган эш көне булган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-ана түләве 1 яшьтән 3 яшькә кадәр – 2853 сум, 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр 3127 сум тәшкил итә.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыруның көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләрен, срокларын һәм этапларын тасвирлау

Хәзерге заман этабында дәүләт гаилә сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр тора:

- хезмәт күрсәтүләрнең комплекслылыгы, һәркем өчен мөмкин булуы;
- хезмәтләр мөрәҗәгать итүченең яшенә, дине, социаль статусы, яшәү урынына бәйсез рәвештә һәм бары тик ирекле тәртиптә генә күрсәтелә;
- консультацияләр клиенттан алынган аның шәхси тормышы турындагы мәгълүматның тулы конфиденциальлеген саклап калуга нигезләнә;
- белгечләрнең югары профессиональлеге;
- клиентлар теләге буенча мөрәҗәгать аноним булырга мөмкин;
- кешелеклелек, игелеклелек, игътибар, шәхси якын килү.

Ярдәмче программаның максаты:

- гаилә һәм гаилә кыйммәтләрен саклау, ныгыту һәм яклау, муниципаль районда гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү;
- Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру;

Ярдәмче программаның бурычлары:

Түбәндәге өлешләрдә муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм чараларын бирү:

муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү

- мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсациятүләүләре;
- гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары системасын үстерү;
- ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру;
- гаиләдә яшәү рәвешенең кыйммәтен һәм иҗтимагый абруен күтәрү, җаваплы ата һәм ана булуны пропагандалау;

- гаилә иминлеге, балалар күзәтүчесезлеген һәм сукбайлыгын профилактикалау.

Максатлар, бурычлар һәм чаралар киселешендә Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында белешмәләр Ярдәмче программага кушымтада бирелгән.

Подпрограмманы тормышка ашыру вакыты: 2021 – 2023 еллар.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 89 909,0 мең сум тәшкил итә, еллар буенча:

| | |
|---|---|
| 2018 ел | 29 277,5 мең сум |
| 2019 ел | 29 960,6 мең сум |
| 2020 ел | 30 670,9 мең сум |

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүгә финанс чыгымнары нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән раслана.

Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның муниципаль заказчысы — Татарстан Республикасы. Подпрограмма чараларын тормышка ашыруда Опека һәм попечительлек бүлеге, Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе катнаша.

Опека һәм попечительлек бүлеге Ярдәмче программаны өлешчә тормышка ашыру өчен җавап бирә:

программа чараларын әзерләү һәм тормышка ашыру, муниципаль районның бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итә,

программа чараларының үтәлешен контрольдә тоту максатыннан оператив һәм статистик хисап алып баруны оештыра.

Опека һәм попечительлек бүлеге хисап кварталыннан соң киләторган айның 10 нчы числосына кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру турында статистик мәгълүмат бирә. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау һәм урнаштыру буенча ай саен 25 нче числога кадәр Республика уллыкка алу, опека һәм попечительлек үзәгенә мониторинг тапшыра.

Мәгариф идарәсе мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен тулысынча компенсацияләүне тәэмин итү буенча Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен җавап бирә;

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе:

чаралар үтәлешен контрольдә тоту;

бүлеп бирелә торган финанс чараларының башкаручылар тарафыннан рациональ кулланылышын контрольдә тоту;

Ярдәмче программа чаралары киселешендә Ярдәмче программаның үтәлеше буенча хисап (квартал, еллык) формалаштыру;

чираттагы финанс елына Ярдәмче программа чараларын ассигнованиеләү өчен җыелма бюджет гаризасын билгеләнгән тәртиптә әзерләү һәм бирү.

Финанслау тәртибе, шулай ук Ярдәмче программада каралган чараларны гамәлгә ашыру механизмы федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән. Ярдәмче программага билгеләнгән тәртиптә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертелә ала.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен компенсация түләүләренә гаризалар теркәү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге тарафыннан үткәрелә. «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе ай саен 2-3 числоларда муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә үткән ай өчен йөргән көннәрне исәпләп, ата-аналар түләве суммасын күрсәтеп, квитанцияләр бирә. Ата-аналар 15 нче числога кадәр ата-аналар түләвен түли, түләү турында чек (күчермәсе) 20 нче числога кадәр мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан «ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесенә бирелә, ул барлык мәгълүматларны «Ата-аналар түләве» АИСына кертә. Ай саен 25-26 нчы числоларда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә мәгълүматлар йөкләнә. «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе 15 нче числога кадәр компенсация түләүләренең исәп-хисаплары ведомостьларын

ала. Алга таба компенсация түләүләрен һәр ата-анага банк счетларына күчерү башкарыла.

Барлык муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары сайтларында «Ата-аналар өчен» рубрикасы астында ата-аналар өчен компенсация түләү буенча актуаль мәгълүмат урнаштырылган. Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре порталында «Компенсация түләүләрен исәпләү» сервисы урнаштырылган, аның ярдәмендә һәр ата-ана гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балаларга ата-ана түләвенең компенсацион түләүләре күләмен исәпләп чыгара ала.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә), гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган балаларның иминлеген арттыру;

ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гражданнар гаиләләренә гарантияле урнаштыру;

әлеге категория балаларын имин һәм уңайлы, яшәү шартларында бала хокуклары үтәлә һәм аның белән рәхимсез мөрәҗәгать итүнең теләсә нинди рәвеше булмаган гаилә тирәлеге белән тәэмин итү;

аны иртә ачыклауга нигезләнгән гаилә иминсезлеген профилактикалауны, авыр тормыш хәлендә булган гаиләгә ярдәм итүне, баланы туган гаиләдә тәрбияләүнең өстенлекле юнәлешләрен профилактикалауны тәэмин итү;

балалы гаиләләр өчен социаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген һәм сыйфатын арттыру,

Ярдәмче программа кысаларында үткәрелә торган чаралар кайбер төп бурычны – гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү; гаиләне ныгыту һәм яклау, җәмгыять тормышында гаиләнең ролен арттыру, гаилә иминсезлеген кисәтү һәм җиңүне хәл итүгә ярдәм итәчәк.

2021 – 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасына кушымта

# 2021 – 2023 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Бурычның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, процентлар | Индикаторның кыйммәте еллар буенча % ларда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| Муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү өлешендә муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның барлык рәвешләрендә бер тапкыр бирелә торган пособиене тулы күләмдә бирү | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | Тәрбиягә алган гаиләгә балаларны карап тоту өчен тулы күләмдә түләү бирү | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | Тәрбиягә бала алган гаиләгә балаларны карап тотуга тулы күләмдә акча бирү | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | Опекуннарның гаиләләренә балаларны карап тотуга тулы күләмдә акча бирү | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының опека һәм попечительлек органнарында оргтехника паркын яңарту | 100 | 100 | 100 |
| | Ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өлеше | 98,8 | 98,8 | 98,8 |
| Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караган | Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүне тулысынча бирү | 100 | 100 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү өлешендә муниципаль районның опека һәм попечительлек органы эшчәнлеген тәэмин итү өлешендә муниципаль район гражданнарының аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында, муниципаль норматив-хокукый актларда билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү | | | | |